ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 141 от «18» 05 2022 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районының «Шәһәр хуҗалыгы»
муниципаль унитар предприятиесе
тарафыннан балалар аттракционнары
хезмәте күрсәтүгә тарифларны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә эшен оештыру принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 17 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2016 елны 08 апрелендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль предприятие һәм учреждениеләре тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләргә һәм эшенә тарифларны билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында», 5-6 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Шәһәр хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан балалар аттракционнары хезмәте күрсәтүгә тарифларны кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 8 апрелендәге 113 нче карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының www.mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М.Дәрҗеманов

0000011408

Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
18.05 2022 ел, № 141
карарына 1 нче кушымта

## Балалар аттракционнары хезмәтләренә һәм спорт инвентарьларын прокатка бирү буенча тарифлар

| Күрсәтелүче хезмәтнең исеме | Халык категориясе | 1 кешегә хезмәттән файдалану дәвамлылыгы | Тариф күләме, сумнарда |
|---|---|---|---|
| «Самолетлар» каруселе | | | |
| | 3 яшьтән 14 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 40 кг кадәр) | 10 минут | 50 |
| «Юлбарыс балалары» каруселе | 8 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 60 килограммга кадәр) | 10 минут | 50 |
| «Космос» каруселе | 3 яшьтән 14 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 40 килограммга кадәр) | 10 минут | 50 |
| «Әйләнүче вертолетлар» каруселе | 5 яшьтән 12 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 40 кг артмаган) | 10 минут | 50 |
| «Паровозлар» каруселе | 1 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 80 килограммга кадәр) | 10 минут | 50 |
| «Тарзанка» аттракционы | 3 яшьтән 12 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 40 кг. артмаган) | 10 минут | 50 |
| Мега батут «Хайваннар дөньясында» | 3 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 65 кг артмаган) | 10 минут | 50 |
| «Аккош көймәсе» каруселе | 5 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 50 килограммга кадәр) | 10 минут | 50 |
| Батут «Тычкан патшасы» | 3 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 65 килограммга кадәр) | 10 минут | 50 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Батут «Әкият» | 3 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 65 килограммга кадәр) | 10 минут | 50 |
| Батут «Джунгли» | 3 яшьтән 16 яшькә кадәр балалар (авырлыклары 65 килограммга кадәр) | 10 минут | 50 |

| Прокат исеме | Халык категориясе | 1 кешегә хезмәттән файдалану дәвамлылыгы | Тариф күләме, сумнарда |
|---|---|---|---|
| Велосипедлар | | | |
| | Чикләүләрсез | 15 минут | 50 |
| Самокатлар | Чикләүләрсез | 15 минут | 50 |
| Гироскутерлар | Чикләүләрсез | 10 минут | 50 |
| Скейбордлар | Чикләүләрсез | 15 минут | 50 |
| Роликлы тимераяклар | Чикләүләрсез | 15 минут | 50 |
| Балалар электромобильләре | 3 яшьтән 14 яшькә кадәр балалар | 5 минут | 50 |
| Катамараннар | Өлкәннәр һәм 14 яшь тулган балалар (14 яшькә кадәр балалар түләүсез) | 30 минут | 100 |
| Көймәләр | Өлкәннәр һәм 14 яшь тулган балалар (14 яшькә кадәр балалар түләүсез) | 30 минут | 100 |